КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 8 ноябрь г.Казань № б-2258

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итү турында» 2021 елның 9 октябрендәге ПУ-800 номерлы Указының 2 пунктын үтәү йөзеннән:

1. Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 2021 елның 15 декабренә кадәр Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү буенча төп чаралар планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

3. Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү буенча төп чаралар планы үтәлешен тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 апрель, б-759 нчы боерыгы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасының цифрлы трансформацияләү проектларын тормышка ашыру буенча эшче төркем тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 ноябрь, б-2258 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында
Цифрлаштыру елын үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, оешгтыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гыйльметдинов Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | Цифрлы нигездә үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясе Советы рәисе (килешү буенча) |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхразыев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары. |